**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Мөслим районының Карл Либкнехт исемендәге авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасы Мөслим районының Карл Либкнехт исемендәге авылы территориясендә;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Азнакай районы Беренче Май поселогының Түбән урамындагы 30 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;

Мөслим районының Елгабаш авылы янындагы, «Органик Групп Урожай» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан мөгезле эре терлек асрау өчен файдаланыла торган территория.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Мөслим районының Карл Либкнехт исемендәге авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 30 октябрендәге ПУ-1038 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 30 декабрь
№ПУ-1272